РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«31» октябрь 2022г. г. Альметьевск № 84

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2016 елның 10 августындагы 42 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре җирле үзидарә органы муниципаль хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәткәр вазифаларын биләүче затлар өчен премияләр бирү һәм башка өстәмә түләүләр турында нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Хокукый мониторинг тәртибендә, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тәкъдимнәре нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Советының 2016 елның 10 августындагы 42 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре җирле үзидарә органы муниципаль хезмәткәрләрен һәм муниципаль хезмәткәр вазифаларын биләүче затлар өчен премияләр бирү һәм башка өстәмә түләүләр турында нигезләмә хакында»гы карарына» (Әлмәт шәһәр Советының 2016 елның 06 октябрендәге 48 номерлы, 2016 елның 28 декабрендәге 61 номерлы, 2018 елның 31 маендагы 121 номерлы, 2019 елның 28 августындагы 167 номерлы, 2021 елның 22 июлендәге 41 номерлы, 2022 елның 13 июлендәге 73 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 2 нче кушымтаның 1 пунктындагы беренче абзацында «..кадәр күләмдә» сүзләрен «..кадәр күләмдә , ....артык булмаган» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Шәйхетдинова Ф.А.).

Шәһәр Башлыгы «АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ» Т.Д. Нагуманов